**ГЛАВА**
**Кичкетанского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Кичкетаң авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.10.2019 Кичкетаң авылы № 6

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кичкетаң авыл җирлеге Кичкетаң авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кичкетаң авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кичкетаң авыл җирлеге башлыгы к а р а р б и р д е:

1 Кичкетаң авыл мәдәният йорты бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2019 елның 25 октябренә 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауные расларга: «I группа инвалидлар, ялгыз яшәүче өлкән кешеләрдән (80 яшькә җиткән), торып укучы студентлардан тыш, Кичкетаң авыл җирлеге Кичкетаң авылында теркәлгән балигъ булган һәр гражданга 2020 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә юнәлтергә Сез ризамы:

1. Авыл җирлеге чикләренә кергән торак пунктларны төзекләндерү өчен МТЗ-82 тракторы сатып алу.

2. Кичкетаң авылы урамнарын кардан чистарту.

«ӘЙЕ» «ЮК".

3. Кичкетан авыл җирлеге Башкарма Комитетына халык җыенын оештыруны һәм уткәрүне йөкләргә.

4. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштыру, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан

Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында.бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

З.Р.НУРИЕВ